Карар № 2                                                                 10.01.2019 ел

“ Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
туган якны өйрәнү музее”
муниципаль бюджет учреждениесе
Уставына үзгәрешләр кертү турында

Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 матдәсенә таянып, Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “ Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы туган якны өйрәнү музее” муниципаль бюджет учреждениесе Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертәргә:

1) 1.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.10. МБУ структурасына керәләр һәм аның филиаллары булып торалар:

- Ә.Ш.Әбдриев исемендәге “Җир һәм кешеләр” музее;

Урнашу адресы: ТР, Чүпрәле районы, Иске Шәйморза авылы, Тукай урамы, 1 йорт;

- П.В. Дементьев музее;

Урнашу адресы: ТР, Чүпрәле районы, Яңа Уби авылы, Тынычлык урамы, 40 йорт”;

2) 3.4 пунктны төшереп калдырырга;

3) 3.5-3.7 пунктларын тәңгәл рәвештә 3.4-3.6 пунктлары итеп санарга;

4) 5.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 5.3.1-5.3.6 подпунктлары белән тулыландырырга:

“5.3.1. Милекне аеруча кыйммәтле күчемле милек категориясенә кертү хакындагы карар күрсәтелгән милекне учреждениегә беркетү хакындагы карар белән бергә кабул ителә.

5.3.2. МБУ га үз уставы бурычларын үтәү өчен кирәк булган җир кишәрлеге аңа даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукында бирелә.

5.3.3.Милек һәм җир кишәрлегенең милекчесе булып “Чүпрәле муниципаль районы” муниципаль берәмлеге тора.

5.3.4.МБУ үзенә беркетелгән милек һәм җир кишәрлегенә карата файдалану һәм эш итү хокукын законнарда һәм милек беркетү хакындагы килешүдә билгеләнгән чикләрдә гамәлгә ашыра.

5.3.5. МБУ ның үзенә беркетелгән яки сатып алу өчен аңа бүлеп бирелгән акчалар хисабына сатып алынган күчемсез һәм аеруча кыйммәтле күчемле милек белән Гамәлгә куючы ризалыгыннан башка идарә итәргә хокукы юк.

5.3.6. Калган милек, шул исәптән күчемсез милек, белән МБУ мөстәкыйль идарә итәргә хокуклы”.

2. “ Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы туган якны өйрәнү музее” муниципаль бюджет учреждениесе Уставын әлеге Карарга кушымта итеп бирелүче яңа редакциядә расларга.

3. “ Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы туган якны өйрәнү музее” муниципаль бюджет учреждениесе директорына яңа редакциядәге Уставны, гамәлдәге законнарга туры китереп, салым органнарында дәүләт теркәвенә документлар тапшырганда гариза бирү вәкаләтен бирергә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазифаларын башкаручы: Д.А.Сатдинов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
_____________________ № _____
Карары белән
расланган.

# “ Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы туган якны өйрәнү музее” муниципаль бюджет учреждениесе

# УСТАВЫ

(яңа редакция)

Иске Чүпрәле ав.
2019

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. “ Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы туган якны өйрәнү музее” муниципаль бюджет учреждениесе социаль-мәдәни, фәнни-тикшеренү һәм укыту-тәрбия, фәнни-методик функцияләрне гамәлгә ашыру; күчемле һәм күчемсез, мәдәни һәм тарихи кыйммәтләрне саклау һәм алардан файдалану өчен Гамәлгә куючылар тарафыннан булдырылган коммерциячел булмаган оешма булып тора.

1.2. “ Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы туган якны өйрәнү музее” муниципаль бюджет учреждениесен (алда – Музей) гамәлгә куючы - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты (алда – Гамәлгә куючы). Гамәлгә куючы Музей эшчәнлеген координацияләү һәм җайга салуны, музей фондларын саклау һәм алардан файдалануның тәэмин ителешенә контрольне гамәлгә ашыра. Музей Гамәлгә куючы алдында хисап тота, ведомствочыл буйсыну ягыннан гамәлдәге законнарда, муниципаль районның хокукый-норматив актларында күздә тотылган тәртиптә “Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге” муниципаль казна учреждениесенә карый.

1.3. Тулы атамасы:

рус телендә: Муниципальное бюджетное учреждение «Краеведческий музей Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан», кыскартылма атамасы «МБУ»;

татар телендә: «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе.

1.4. МБУ юридик зат булып тора; үз эченә структур бүлекчәне (филиал) керткән административ берәмлекләрдән тора; аерымланган мөлкәткә, үз атамасына, мөстәкыйль балланска, сметага, кредит оешмаларында исәп-хисап һәм башка счетларга, билгеләнгән үрнәктәге мөһер, штамп, бланкларга ия.

1.5. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китереп, МБУ коммерциячел булмаган оешма булып тора, үз исеменнән мөлкәти хокукларын гамәлгә ашыра, үз йөкләмәләренә ия, судта дәгъвачы һәм җавапка тартылучы булырга хокуклы.

1.6. МБУ, үз составына керүче филиалларның территориаль урнашуына бәйсез рәвештә, функцияләрен бердәм административ һәм методик җитәкчелек, уртак милек фонды һәм штатлар, үзәкләштерелгән технологик процесслар нигезендә башкаручы структур яктан бөтен учреждение.

1.7. МБУ үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясенә таянып; “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында”гы 25.06.2002 ел № 73-ФЗ Федераль законына; 09.10.1992 ел №3612-1 “Мәдәният турындагы Россия Федерациясе законнары нигезләре»нә; “Россия Федерациясенең музей фонды һәм Россия Федерациясе музейлары турында”гы 26.05.1996 ел Федераль законына; “Мәдәни һәм тарихи кыйммәтләрне саклау һәм файдалану турында”гы 02.10.1996 ел №755 Татарстан Республикасы Законына; “Мәдәният турында” гы 03.07.1998 ел №1705 Татарстан Республикасы Законына; Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 27.04.1996 ел №345 Карары белән расланган Татарстан Республикасында мәдәният һәм сәнгать оешмаларының хуҗалык эшчәнлеге нигезләре һәм аны финанслау турындагы Нигезләмәгә; «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 06.10.2003 ел 131-ФЗ Федераль законына; "Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында"гы 01.04.2005 ел №60-З РТ Татарстан Республикасы Законына; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.01.2007 ел №94-Р Боерыгына; Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарының башка норматив хокукый актларына туры китереп алып бара.

1.8. МБУ Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты средстволарыннан финанслана.

МБУ үз эшчәнлеген Уставта билгеләнгән максат һәм бурычлардан чыгып; үзендә булган иҗат һәм хуҗалык ресурсларын, МБУның иҗади-җитештерү һәм социаль үсеше перспективаларын исәпкә алып планлаштыра.

1.9. МБУның юридик адресы һәм урнашкан урыны:

422470, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле авылы, Дзержинский урамы, йорт № 3.

1.10. МБУ структурасына керәләр һәм аның филиаллары булып торалар:

- Ә.Ш.Әбдриев исемендәге "Җир һәм кешеләр" музее;

Урнашу адресы: ТР, Чүпрәле районы, Иске Шәйморза авылы, Тукай урамы, йорт №1;

- П.В. Дементьев музее;

Урнашу адресы: ТР, Чүпрәле районы, Яңа Уби авылы, Тынычлык урамы, йорт №40.

## 2. Максатлары, бурычлары һәм эшчәнлек предметы

2.1. МБУ фәнни-тикшеренү һәм фәнни-агарту учреждениесы, күчемле һәм күчемсез мәдәни һәм тарихи кыйммәтләрне саклау оешмасы булып тора.

2.2. МБУ эшчәнлеге предметы булып түбәндәгеләр тора:

- тарих һәм мәдәниятның тарихи, фәнни, архитектур, сәнгати, мемориаль һәм мәдәни яктан башка аерым кыйммәтләргә ия булган күчемсез ядкәрләрен комплекслы өйрәнү, популярлаштыру һәм музей максатларында файдалану;

-фәнни-тикшеренү эшчәнлеге;

-фәнни-методик эшчәнлек;

- экспозицион-күргәзмә эшчәнлеге;

-җыю эшчәнлеге;

-административ-хуҗалык эшләре;

-күчемле мәдәни һәм тарихи байлыкны реконструкцияләү, консервацияләү, реставрацияләү, пропагандалау һәм популярлаштыру;

2.3.МБУ эшчәнлегенең төп максатлары һәм бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

-күчемле һәм күчемсез тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау, өйрәнү һәм файдалану өчен уңайлы шартлар булдыру;

-мәдәни һәм табигый мирасны музей средстволары (экспозицииләр, күргәзмәләр, экскурсияләр, лекцияләр һ.б.) ярдәмендә популярлаштыру;

-халыкта эстетик ихтыяҗ формалаштыру һәм аны кәнагәтьләндерү;

2.4. Районлагы тарих, архитектура һәм мәдәни мирас һәйкәлләрен саклау һәм файдалануны тәэмин итү өчен:

-билгеләнгән тәртиптә археологик һәм башка фәнни экспедицияләр оештыра һәм үткәрә; мәдәни мирас объектларын исәпкә ала һәм паспортлаштыра, аларны мәдәният тарихы һәйкәлләре исемлегенә кертү турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертә;

-район территориясендәге ТРның Мәдәни һәм тарихи һәйкәлләр реестрына кергән архитектура һәйкәлләрен карап тору режимын әзерләүдә катнаша;

-район территориясендә булган мәдәни мирас объектларына карата хокук бозуларны кисәтү яки туктату буенча барлык кирәкле чараларны күрә, ачыкланган хокук бозу фактлары һәм күрелгән чаралар хакында кичекмәстән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау һәм куллануга дәүләт контроле баш идарәсенә хәбәр итә;

-тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрдән файдалануның торышына һәм билгеләнгән хокукый режимның, кагыйдәләрнең үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыра;

-тарихи-мәдәни мирас объектларында проектлау, реставрацияләү, ремонтлау эшләре һәм башка эшләр барышына методик, оператив контрольне гамәлгә ашыра;

-мәдәни мирас объектларының сакланышына куркыныч янаганда теләсә нинди төрдәге эшләрне һәм хуҗалык эшчәнлеген туктату мәсьәләләрен карый һәм үз компетенциясе чикләрендә карар кабул итә;

2.5. МБУның фәнни-тикшеренү функциясе туган авыл халкының аның күзаллау мөмкин булган тарихындагы икътисади, сәяси, социаль һәм мәдәни үсешен фәнни өйрәнү юлы белән башкарыла.

2.6. Үзендәге тупланмалар профиле буенча МБУ үз эченә түбәндәге юнәлешләрне эченә алган фәнни-тикшеренү эшләрен гамәлгә ашыра:

-МБУ коллекцияләрен фәнни үзләштерү;

-тарихи-мәдәни мирас проблемаларына багышланган фәнни мәкаләләр әзерләү;

- тарихи-мәдәни мирас турында фәнни-практик конференцияләр, массакүләм мәдәни чаралар, семинарлар, түгәрәк өстәлләр үткәрү;

- МБУ район тарихын фәнни тикшерүләргә үз өлешен кертә. Фәнни тикшерүләр барышында тупланган мәгълүматны МБУ үз экспозицияләре һәм ММЧ аша популярлаштыра;

-МБУ ның укыту-тәрбия функциясе район халыклары тарихына фәнни караш формалаштырудан һәм халыкларның рухи тормышын баетудан гыйбәрәт.

2.7.МБУ ның фәнни-тикшеренү эшләре нәтиҗәләре булып тематик-экспозицион планнар, экспедицияләр буенча фәнни хисаплар, аерым әсәр һәм

коллекцияләрне фәнни тасвирлау, туган авылны өйрәнү буенча монография эшләре, аерым күчемле һәм күчемсез ядкәрләр турындагы мәкаләләр, музей эше өлкәсенә караган фәнни-методик эшләр тора;

2.8.МБУ ның экспозицион-күргәзмә эшчәнлеге перспектив һәм еллык планнарга туры китереп алып барыла, алар нигезендә тематик-экспозицион планнар һәм даими экспозицияләрне, вакытлы күргәзмәләрне сәнгати бизәү проектлары төзелә. Биредә аларны сыйфатлы музей әсбаплары (стендлар, витриналар һ.б.) белән тәэмин итү күздә тотыла.

2.9.МБУ ның экспозицион эшчәнлеге тарих фәне казанышларын һәм музей эшенең хәзерге заман принципларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла. МБУ даими экспозицияләренең төп бурычы булып ватан тарихы һәм мәдәнияты үсешенең фәнни нигезләнгән картинасын булдыру тора. Яңа күренекле күчемле мәдәни байлык кергән саен яки музей фондларындагы предметларны күргәзмәгә әзерләгәндә МБУ экспозицияләре яңартылырга, тулыландырылырга яки тулаем үзгәртеп корылырга мөмкин. Халык сәнгати промыселларын, декоратив-гамәли сәнгатьне үстерү, популярлаштыру һәм аларга ярдәм итү максатында МБУ сынлы һәм декоратив-гамәли  сәнгать әсәрләреннән даими күргәзмә-ярминкәләр үткәрә.

2.10.МБУ регуляр рәвештә күчемле мәдәни байлык үрнәкләреннән, сынлы һәм декоратив-гамәли  сәнгать эшләнмәләреннән вакытлы күргәзмәләр үткәрә, моның өчен үз фондларыннан, башка музей, учреждениеләр материалларыннан, шәхси тупланмалардан файдалана. Музей күргәзмәләренең тематикасы күренекле тарихи һәм мәдәни вакыйгаларга, хәзерге заман чынбарлыгына, җирле декоратив-гамәли  сәнгать осталары һәм рәссамнар иҗатына; башка районнар, өлкәләр, Россия Федерациясе республикалары осталары һәм рәссамнары иҗатына багышланырга мөмкин. Күргәзмәләр шәхси, төркемле, юбилей уңаеннан, тематик һәм башкача итеп үткәрелергә мөмкин.

2.11. Экспозицион-күргәзмә эшчәнлекне пропагандалау формалары булып:

-китап бастыру:

-даими экспозицияләрне һәм вакытлы күргәзмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту;

-МБУ га килүчеләргә экскурсион хезмәт күрсәтүне оештыру;

- консультацияләр үткәрү тора.

2.12. Коллекцияләр комплектлау максатында МБУ башка музейлар, коллекционерлар белән контактта тора; матди һәм рухи мәдәният һәйкәлләрен җыю буенча экспедицияләр оештыра.

2.13.Җыю-туплау эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм музей коллекцияләренең сакланышын тәэмин итү өчен МБУ:

-үзендәге матди һәм рухи мәдәният ядкәрләре тупланмасын “Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге” муниципаль казна учреждениесе комиссиясе тарафыннан расланган предметлар белән тулыландыра;

-музей коллекцияләрендә булган предметларның исәбен алып бара һәм аларны саклауны оештыра;

-фондлар оештыра һәм аларны фәнни инвентаризацияләү үткәрә;

-фондларның күчеп йөрүен теркәп бара;

-исәп-хисап, саклау, реставрация эшләрен яхшырту буенча чаралар оештыра һәм үткәрә;

-музей предметларының алмаш фондын булдыра;

-башка кирәкле чараларны гамәлгә ашыра.

2.14.МБУ методик эшчәнлегенең төп формалары булып:

-хезмәт күрсәтүне карарга килүчеләр ихтыяҗларын исәпкә алып оештыру; аларга Чүпрәле районы халыкларының мәдәнияты, көнкүреше буенча информацияләр, тарихи мәгълүматлар белән якыннан танышу мөмкинлеге тудыру тора.

2.15.Район кешеләре арасында этнография, археология, география буенча мәгълүматларны тарату. Үсеп баручы буынның әхлакый үсешенә, аларның белем дәрәҗәсе, иҗади сәләте артуына булышлык итү.

2.16.Төп эшчәнлегеннән тыш, МБУ гамәлдәге законнарга каршы килмәгән, Уставта күздә тотылган башка, шул исәптән эшмәкәрлек, эшчәнлеге дә алып бара ала:

-төп эшчәнлек буенча өстәмә түләүле хезмәт күрсәтү;

-мәгълүмати-белешмә хезмәте;

-лекцион һәм күргәзмә эшчәнлеге;

-күргәзмә-ярминкәләр оештыру;

-тарих, туган якны өйрәнү, этнография, декоратив-гамәли сәнгать, музей эше өлкәсе буенча консультацион хезмәт күрсәтү;

-экскурсион хезмәт күрсәтү;

-тантаналы чаралар үткәрүдә катнашу;

-басма эшләнмәләр, сәнгати сувенирлар, декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләре сату;

-халыкка һәм оешмаларга башка төр хезмәт күрсәтү.

2.17.Алынган табыш тулысы белән Уставта каралган бурычларны тормышка ашыру, шулай ук МБУ эшчәнлеге формаларын баету һәм камилләштерү максатларына тотылса, мәдәни һәм экскурсион эшчәнлекнең теләсә кайсы формасы да эшмәкәрлек дип каралмый.

## 3.Идарә итү

3.1.МБУ белән идарә итү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына һәм әлеге Уставка туры китереп башкарыла.

3.2.Гамәлгә куючы МБУ Уставын һәм Уставка үзгәрешләр кертүне раслый, МБУ эшчәнлегенең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, гамәлгә кую документларына туры килүен контрольдә тота.

3.3.МБУ эшчәнлеге сугышны, рәхимсезлек һәм көч куллануны, расачыл, милли, дини, сыйнфый яки башка төр күрә алмаучылыкны пропагандалауга алып барган очраклардан кала, Гамәлгә куючы бу эшчәнлеккә катнашмый.

3.4.МБУ директоры Уставка туры китереп һәм үз компетенциясе чикләрендә МБУ исеменнән ышаныч кәгазеннән башка эш итә; юридик һәм

физик затлар белән мөнәсәбәтләрдә аның мәнфәгатьләрен тәкъдим итә; Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарында, әлеге Уставта билгеләнгән чикләрдә МБУ милке һәм средстволары белән идарә итә; килешүләр, шул исәптән хезмәт килешүләре төзи; ышаныч кәгазьләре бирә; средстволар белән идарә итү хокукыннан файдалана; структура һәм штатлар расписаниесен раслый; үз компетенциясе чикләрендә МБУ ның барлык хезмәткәрләре өчен үтәлеше мәҗбүри булган боерыклар чыгара һәм күрсәтмәләр бирә; МБУ эшчәнлеге нәтиҗәләре өчен шәхси җавап тота.

3.5. МБУ хезмәткәрләре вазифалары тиешле белем дәрәҗәсе һәм профиленә туры китереп биләнә.

3.6.МБУ хезмәткәрләре МБУ хезмәткәрләрен аттестацияләү турындагы Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә системалы рәвештә аттестация узалар.

## 4.Төп хокуклары һәм бурычлары

4.1.Үз эшчәнлегендә МБУ гамәлдәге законнарда каралган хокуклардан файдалана.

Устав максатларын үтәү өчен МБУ түбәндәгеләргә хокуклы:

-музей өчен әһәмияте булган предметлар сатып алырга:

-үзендә булган финанс ресурслары, вакытлы ярдәм, билгеләнгән тәртиптә алда күрсәтелгән максатларда алынган ссуда һәм кредитлар хисабына төп һәм әйләнештәге средстволар сатып алырга яки арендаларга;

-хәйрия оешмаларыннан һәм башка оешмалардан, юридик һәм физик затлардан акча средстволарын һәм матди байлыкны бушлай кабул итәргә:

-үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен килешү нигезендә юридик һәм физик затлар җәлеп итәргә;

- МБУ ның эшмәкәрлек эшчәнлеген тормышка ашыру өчен Устав чикләрендә һәм Гамәлгә куючы карары белән структур берәмлекләр булдырырга;

- продукциягә, хезмәтләргә кулланучылар сорауыннан чыгып һәм төзелгән килешүләр нигезендә, Гамәлгә куючы белән килештереп, үз эшчәнлеген планлаштырырга һәм үсеш перспективаларын билгеләргә;

-законнарда һәм милек беркетү турындагы килешүдә каралган тәртиптә һәм чикләрдә үз эшчәнлеге максатларына туры китереп милеккә, төп, ярдәмче, алмаш һәм дублет фондларга ия булырга, алардан файдаланырга һәм алар белән идарә итәргә;

-устав максатлары нигезендә эшчәнлекнең төп төрләрен гамәлгә ашыру, хезмәткәрләрне бүләкләү һәм аларга матди ярдәм күрсәтү өчен түләүле хезмәтләрдән һәм эшмәкәрлектән кергән акча средстволарын сарыф итәргә;

-үз эшчәнлеге максатларында килешүләр, шул исәптән юридик һәм физик затлар белән, төзергә һәм башка алыш-биреш гамәлләрен башкарырга;

-устав максатларына туры китереп күрсәткән хезмәтләрен гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә расланган бәяләр һәм тарифлар нигезендә реализацияләргә;

- Гамәлгә куючы белән килештереп структура һәм штатлар расписаниесен төзергә һәм расларга;

-халыкка түләүле хезмәт күрсәтергә;

-халыкның гамәлдәге законнарда каралган категорияләренә, шулай ук оешмалар сорауы буенча башка затларга МБУ ның түләүле хезмәтләренә ташламалар билгеләргә;

-реклама максатында һәм уставта каралган башка максатларда үз символикасын файдаланырга;

-фәнни тикшеренү юнәлешендәге мәкаләләр, мәгълүматлар бастырырга; фәнни эшләр һәм аларның җыентыкларын, фәнни-белешмә, методик әдәбият, афишалар һәм башка төр реклама эшләнмәләрен реализацияләргә;

-гамәлдәге законнарда каралган башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

4.2. МБУ бурычлы:

-тарихи-җитештерү эшчәнлеге һәм социаль үсеш мәсьәләләрен чишкәндә МБУ хезмәткәрләренең инициативлылыгын үстерүгә булышлык итәргә;

-милектән эффектлы файдаланырга;

-милекнең сакланышын һәм аны катгый рәвештә максатка ярашлы итеп файдалануны тәэмин итәргә;

-тиешле бюджет финанслары бүленеп бирелгәндә милеккә капиталь һәм агымдагы ремонт ясауны гамәлгә ашырырга;

-үз хезмәткәрләрен куркынычсыз хезмәт шартлары белән тәэмин итәргә һәм билгеләнгән тәртиптә аларның сәламәтлегенә һәм эшкә сәләтлелегенә зыян китерелгән өчен җаваплы булырга;

-бюджет акчаларын катгый рәвештә расланган бүленеш һәм лимитларга туры китереп сарыф итәргә;

-МБУ әлеге Уставта каралганча мөстәкыйль хуҗалык эшчәнлеге алып барырга һәм бу эшчәнлектән кергән керем белән идарә итәргә хокуклы;

-МБУ ның матди-техник базасын ныгытырга;

-техника, янгын куркынычсызлыгын һәм милекне саклауны тәэмин итәргә;

-“Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге” муниципаль казна учреждениесенә тулысы белән расланган формаларда һәм эшчәнлекнең барлык төрләре буенча тиешле смета-финанс документациясен тапшырырга;

-эш кәгазьләренең (идарә, финанс-хуҗалык, шәхси состав документлары һ.б. документлар) сакланышы өчен җаваплы булырга;

- эш кәгазьләренең килешенгән исемлеге нигезендә фәнни-тарихи әһәмияткә ия булган документларны архив фондларына дәүләт саклауына тапшыруны тәэмин итәргә;

-шәхси состав документларын билгеләнгән тәртиптә сакларга, кулланырга.

4.3.МБУ га оператив идарә итү хокукында беркетелгән милектән файдалануны һәм аның белән идарә итүне “Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге” муниципаль казна учреждениесе контрольдә тота.

## 5. Саклау фондлары, милек һәм аларны оештыру чыганаклары.

5.1.Үз эченә сынлы сәнгать, графика, скульптура, декоратив-гамәли сәнгать коллекцияләрен, археологик материалларны, китапханә һәм архив тупланмаларын алган; куллану әһәмиятенә, мәдәни, социаль һәм башка әһәмияткә ия булган; МБУ ның устав буенча эшчәнлеген тәэмин итү һәм саклау өчен аңа тапшырылган мәдәни һәм тарихи, күчемле һәм күчемсез милек дәүләт милке булып тора.

5.2. Музей фондлары әлеге Уставта билгеләнгән максатларга туры килгән аерым режимда сакланылырга тиешле һәм МБУ балансындагы милек составына кермәүче, хисап-саклау документларында исәпләнүче объектлар булып тора.

5.3.МБУ га устав буенча эшчәнлеген тәэмин итү өчен тапшырылган милек Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль милке булып тора һәм МБУ га оператив идарә итү хокукында беркетелә.

5.3.1. Милекне аеруча кыйммәтле күчемле милек категориясенә кертү хакындагы карар күрсәтелгән милекне учреждениегә беркетү хакындагы карар белән бергә кабул ителә.

5.3.2. МБУ га үз уставы бурычларын үтәү өчен кирәк булган җир кишәрлеге аңа даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукында бирелә.

5.3.3.Милек һәм җир кишәрлегенең милекчесе булып “Чүпрәле муниципаль районы” муниципаль берәмлеге тора.

5.3.4.МБУ үзенә беркетелгән милек һәм җир кишәрлегенә карата файдалану һәм эш итү хокукын законнарда һәм милек беркетү хакындагы килешүдә билгеләнгән чикләрдә гамәлгә ашыра.

5.3.5. МБУ ның үзенә беркетелгән яки сатып алу өчен аңа бүлеп бирелгән акчалар хисабына сатып алынган күчемсез һәм аеруча кыйммәтле күчемле милек белән Гамәлгә куючы ризалыгыннан башка идарә итәргә хокукы юк.

5.3.6. Калган милек, шул исәптән күчемсез милек, белән МБУ мөстәкыйль идарә итәргә хокуклы.

5.4.МБУ милкен һәм финанс ресурсларын формалаштыру чыганаклары булып бюджет һәм бюджеттан тыш средстволар, шул исәптән:

- Муниципаль район бюджетыннан кертемнәр;
- Аңа милекче (яки аның вәкиле) тарафыннан тапшырылган милек;
- Эшләнмәләрне сатудан, хезмәт күрсәтүдән, шулай ук хуҗалык эшчәнлегенең башка рөхсәт ителгән төрләреннән алынган керем;
- Физик һәм юридик затларның иганәчелек кертемнәре.

5.5.МБУ милек белән күчемсез милеккә һәм аның астындагы җир кишәрлегенә хокукы билгеләнгән тәртиптә теркәлү узу нигезендә идарә итә һәм аннан файдалана.

## 6.Исәп һәм хисап алып бару

6.1.МБУ үз эшенең нәтиҗәләренә оператив һәм бухгалтерлык исәп-хисабы, билгеләнгән формада статистик һәм бухгалтерлык хисабы алып бара;

Гамәлгә куючыга хисапны билгеләнгән формалар буенча тулы күләмдә, билгеләнгән срокларда, тапшыра.

6.2.Вазифаи затлар дәүләт хисаплылыгын бозган өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары билгеләгәнчә дисциплинар, матди яки җинаять җаваплылыгы тота.

6.3.МБУ шәхси состав документларын исәпкә алып баруны һәм аларның сакланышын, шулай ук яңадан оештырылу һәм бетерелү очракларында аларның үз вакытында дәүләт саклауына тапшырылуын тәэмин итә.

## 7. Яңадан оештырылу һәм бетерелү

7.1. МБУ ны яңадан оештыру (кушылу, кушу, бүлү, аеру, үзгәртү формаларында) һәм бетерү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарында каралган тәртиптә яки суд карары буенча гамәлгә ашырыла.

7.2. МБУ ны бетерү нәтиҗәсендә калган милек, бюджет, кредиторлар, МБУ хезмәткәрләре белән билгеләнгән тәртиптә исәп-хисап башкарылганнан соң, муниципаль район милкенә күчә.

МБУ га беркетелгән предметлар һәм музей коллекцияләре, Россия Федерациясенең музейлар һәм музей фондлары турындагы законнарына туры китереп, башка дәүләт музейларына тапшырыла.

7.3.МБУ ны яңадан оештырганда барлык документлар (идарә, финанс-хуҗалык, шәхси состав документлары һ.б.) законнарга туры китереп варис учреждениегә тапшырыла.

7.4.МБУ бетерелгәндә даими сакланыштагы документлар, фәнни-тарихи әһәмияткә ия документлар, шәхси состав документлары (боерыклар, шәхси эшләр, исәп карточкалары, шәхси счетлар һәм башкалар) районның архив фондына саклауга тапшырыла.

7.5. МБУ ны яңадан оештырганда һәм бетергәндә эштән җибәрелүче хезмәткәрләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлдәге законнарга туры китереп үтәү гарантияләнә.

Яңадан оештырылу нәтиҗәсендә МБУ эшчәнлегенең максатларын үзгәртү рөхсәт ителми.

7.6.Бетерелү Гамәлгә куючы тарафыннан юридик затларга дәүләт теркәүен башкаручы орган белән килештереп төзелгән ликвидация комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7.7. Музей яңадан оештырылган яки бетерелгән дип Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшерелеп калдырылган моменттан санала.

## 8. Мәнфәгатьләр конфликтын кисәтү һәм җайга салу

8.1. Мәнфәгатьләр конфликты дип МБУ хезмәткәренең шәхси мәнфәгатьләре аның хезмәт вазифаларын тиешенчә башкаруына йогынты ясаганда һәм бу вакытта МБУ хезмәткәренең шәхси мәнфәгатьләре белән ул

эшләгән МБУ ның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында МБУ милкенә һәм (яки) аның эшлекле репутациясенә зыян салырдай каршылыклар килеп чыкканда яки килеп чыгарга мөмкин булганда барлыкка килгән вәзгыять кабул ителә.

8.2.МБУ хезмәткәренең аның хезмәт вазифаларын тиешенчә башкаруына йогынты ясаучы яки ясарга мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләре дип МБУ хезмәткәренең хезмәт вазифаларын башкаруына бәйле рәвештә үзенә яки башка затларга акчалата керем, байлык, башка милек, шул исәптән милеккә хокук яки милеккә кагылышлы хезмәтләр алуы мөмкин булган мәнфәгатьләре кабул ителә.

8.3.МБУ директоры вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына алып баручы яки алып баруы мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүе хакында эш бирүчегә (Гамәлгә куючыга) хәбәр итәргә бурычлы.

8.4.МБУ хезмәткәре вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына алып баручы яки алып баруы мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килүе хакында МБУ директорына хәбәр итәргә бурычлы. Хәбәр итү тәртибе, хәбәрләрдә булырга тиешле мәгълүматлар исемлеге, бу мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрләрне теркәү тәртибе МБУ директоры тарафыннан билгеләнә.